ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

13.08.2021

№ 1156

«Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрүгә «Алабуга» МИЗ ППТ» АҖ Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 23 июнендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләүгә финанс ярдәме күрсәтү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 1451 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 28 маендагы 435 номерлы карары нигезендә, 2016 елның 7 декабрендәге 01/МИЗ-1210/16 номерлы концессион килешүне гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрүгә «Алабуга» МИЗ ППТ» АҖ Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 23 июнендәге 732 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   1.1. Тәртипнең 6 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

   «Субсидиянең гомуми (чик) күләме коммуналь инфраструктура объектларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү буенча (расланган проект документлары булганда) чараларының смета бәясеннән югарырак билгеләнә алмый яисә өстәмә бәягә салымны исәпкә алмыйча, коммуналь инфраструктура объектларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү буенча чараларның фаразланган (чик) бәясе»

2. Әлеге карар Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов